# КАРАР
## Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Яшелчә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

02 нче декабрь 2020 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 нчы елның 02 нче декабрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясе Яшелчә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1900 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Яшелчә авылы зираты коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);

- Яшелчә авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү килешү буенча).

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 35 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 24 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 24 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенә керүче Яшелчә авылы халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясе Яшелчә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1900 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Яшелчә авылы зираты коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);

- Яшелчә авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү килешү буенча) соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. 2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясе Яшелчә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1900 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

- Яшелчә авылы зираты коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);

- Яшелчә авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү килешү буенча).

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9 йорт;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Гагарин урамы, авыл клубы бинасы, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Кече Салтык авыл җирлеге
башлыгы: А.Г. Җиһаншин